ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» декабрь 2022 ел № 348

"Әгерҗе муниципаль районында "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" МБУ хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм аны оештыру турында" 30.04.2019 елның 168 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмен арттыру турында " 17.09.2022 елның 1013 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында " 30.03.2018 елның 195 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.08.2022 елның 03-16/5605 номерлы хаты, "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" 26.04.2018 елның 194 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.11.2022 елның 299 номерлы карары нигезендә,Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Әгерҗе муниципаль районында «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУ хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм аны оештыру турында» 30.04.2019 елның 168 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып

чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **Р.Р. Шәрипов**

Татарстан Республикасы Әгерже
муниципаль районы Башкарма
комитетының
29.12.2022 № 348 карары белән
расланды

**"Әгерже муниципаль районында "Үзәкләштерелгән бухгалтерия" МБУ хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм аны оештыру турында" 30.04.2019 елның 168 номерлы Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр**

1. Әгерже муниципаль районынын «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитетының 30.04.2019 елның 168 номерлы карары белән расланган «Әгерже муниципаль районында «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУ хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында»» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

Татарстан Республикасы Әгерже
муниципаль районы Башкарма
комитетының 30.04.2019 елның 168
номерлы карары белән расланды

**Әгерже муниципаль районы Үзәкләштерелгән бухгалтерия МБУ хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында нигезләмә**

1. Әгерже муниципаль районы Үзәкләштерелгән бухгалтерия МБУ хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары һәм оештыру турындагы әлеге нигезләмә Әгерже муниципаль районынын Үзәкләштерелгән бухгалтерия МБУ эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.
2. Әгерже муниципаль районы Үзәкләштерелгән бухгалтерия МБУ хезмәткәрләренең хезмәт хакы вазыйфа окладыннан, тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.
3. Әгерже муниципаль районы Үзәкләштерелгән бухгалтерия МБУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфа окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Җитәкче һәм белгеч вазыйфалары | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 27700 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 25500 |

| | |
|---|---|
| Бүлек җитәкчесе | 21700 |
| I нче категорияле бухгалтер | 19300 |
| Бухгалтер | 18000 |
| Персонал буенча белгеч | 19300 |
| Система администраторы | 19300 |

4. Әгерҗе муниципаль районы Үзәкләштерелгән бухгалтерия МБУ җитәкчеләренә һәм белгечләренә билгеләнә:

1) тиешле еллар өчен түбәндәге күләмдә хезмәт хакына айлык өстәмә:

| Эш стажы | Айлык өстәмәләр, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) хезмәт окладының 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен айлык хезмәт хакына өстәмә;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә еллык хезмәт хакының 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Әгәр хезмәткәргә календарь елы дәвамында ел саен түләнә торган отпуск бирелмәгән булса, бер тапкыр бирелә торган түләү декабрьдә пропорциональ рәвештә эшләнгән вакытка, эштән киткән очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Еллык түләүле отпуск биргәндә хезмәткәргә бер тапкыр түләнә торган түләү беренче эш елында календарь елда башкарылган чорга пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы календарь елның 31 декабре буенча эшкә кергән көннән исәпләнә.

4) билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

5) эш нәтиҗәләре буенча премия бер ай һәм квартал өчен исәпләнә.

5. Әгерҗе муниципаль районы Үзәкләштерелгән бухгалтерия МБУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең еллык хезмәт хакы фонды формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} P * (1 + t);$$

где:

$FOT$ – годовой фонд заработной платы руководителей и специалистов;

$O_d$ – сумма средств на выплату должностных окладов руководителю и специалисту в месяц;

$0{,}3 * O_d$ – сумма средств на выплату ежемесячной надбавки к должностному окладу за выслугу лет, ежемесячной надбавки к должностному окладу за интенсивность работы, денежного поощрения, единовременной выплаты при предоставлении ежегодного оплачиваемого отпуска, материальной помощи;

Р – годовой премиальный фонд руководителей и специалистов (определяемый исходя из условий, установленных подпунктом 5 пункта 3 настоящего Положения);

$n$ – штатная численность руководителей и специалистов;

$k$ – 12 месяцев;

$t$ – начисления на выплаты по оплате труда.

»

2. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Әгерҗе муниципаль районында «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МБУ хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм аны оештыру һәм түләү шартлары турында " 30.04.2019 елның 168 номерлы карары белән расланган Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетларының баш бухгалтерлары хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. Нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргәи:

«3. Бухгалтерларның хезмәт хакы түбәндәге зурлыкта билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны 3,5 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары |
|---|---|
| Бухгалтер | 18000 |

»